ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail:KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Карар** **Постановление**

« 31» января 2020 ел № 4

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм 2020 нче елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. 3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы Рәисе И.Н.Салахутдинов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31 гыйнвар 2020 ел, 4 нче
санлы карарына
2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә күмү
урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше,
якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 874,10 |
| 3.Гүргә индерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2023,36 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 749,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2478,40 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы Рәисе И.Н.Салахутдинов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31 гыйнвар 2020 ел, 4 нче санлы карарына
1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| Гүргә иңдерүгә кабер тakталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2817,46 |
| Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 734,13 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2573,27 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы Рәисе И.Н.Салахутдинов